СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

Яңа Кишет авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

“ 09 ” декабрь 2020 ел №11

Яңа Кишет авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 декабрендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Яңа Кишет авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр керту хакында (16.04.2019 ел,№23, 08.11.2019 ел, №39, 20.02.2020 ел, №44, 14.08.2020 ел, № 53 үзгәрешләр белән)

2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр керту хакында" Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль район Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Яңа Кишет авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 декабрендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Яңа Кишет авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (16.04.2019 ел, №23, 08.11.2019 ел, №39, 20.02.2020 ел, №44, 14.08.2020 ел, № 53 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 10.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәрнең урынбасары тиешле вазыйфа биләгән вакытта, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау максатыннан, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмый.";

2) 30 статьяның 30.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30.4. муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Э.Ф.Минзянова